| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ** |

| | | |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | г. Казань | **БОЕРЫК** |
| 28.02.2022 | | 155-п |

Төбәк дәүләт экология тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга бирелә торган җаваплар тикшерүдә тотыла торган затның зарури таләпләрне үтәве яки үтәмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге) үрнәген раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту һәм муниципаль тикшерүдә тоту турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ санлы федераль законның 53 статьясы, РФ Хөкүмәтенең «Тикшерү кәгазьләре үрнәкләре проектларын эшләү, аларның эчтәлегенә, алар турында иҗтимагый фикер алышуга, тикшерү кәгазьләре үрнәкләрен раслау, куллану, актуальләштерүгә карата таләпләр, шулай ук тикшерү кәгазьләрен зарури куллану очракларын раслау турында» 2021 елның 27 октябрендәге 1844 санлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Төбәк дәүләт экология тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга бирелә торган җаваплар тикшерүдә тотыла торган затның зарури таләпләрне үтәве яки үтәмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге) үрнәген расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары А.М.Шиһаповны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы Экология
һәм табигать ресурслары
министрлыгының 28.02.2022
№ 155-пбоерыгы белән расланды

Үрнәк

QR-код

Төбәк дәүләт экология тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту кысаларында кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга бирелгән җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге)

1. Төбәк дәүләт экология тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту кысаларында кулланыла торган әлеге тикшерү кәгазе (аларга бирелгән җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге) (алга таба – тикшерү кәгазе) Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан эшчәнлек башкара торган, ул вакытта әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә зарури таләпләр үтәлергә тиешле юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата күчмә тикшерү уздыру барышында зарури тәртиптә кулланыла.

Күчмә тикшерүнең асылы Министрлык тарафыннан расланган тикшерү кәгазе үрнәгендә күрсәтелгән зарури таләпләр белән чикләнә.

2. Тикшерүдә (күзәтчелектә) тоту органы атамасы – Министрлык.

3. Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту төренең атамасы – төбәк дәүләт экология тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту.

4. Тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чарасының төре ___________________________

5. Тикшерү битен тутыру көне ____________________________________________

6. Үзенә карата тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чарасы үткәрелә торган төбәк дәүләт геология тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту объекты: _______________ _____________________________________________________________________________

7. Тикшерүдә тотылучы затлар булып торган юридик затның атамасы яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) _______________

___________________________________________________________________________

8. Тикшерүдә тотылучы затлар булып торган юридик затның яки шәхси эшкуарның шәхси тәңгәллек саны һәм (яки) төп дәүләт теркәү саны _______________

9. Тикшерүдә тотылучы затлар булып торган юридик затның юридик адресы яки шәхси эшкуарның теркәлү адресы _________________________________________

10. Тикшерү кәгазен тутырып тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чарасын үткәрү урыны (урыннары) _________________________________________

11. Тикшерүдә (күзәтчелектә) тоту чарасын уздыру турында вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзаланган Министрлык карары белешмәләре ________________;

12. Контрольлек (күзәтчелек) чарасының исәпкә алу саны __________________

13. Тикшерүдә тоту тәре турындагы нигезләмә, вазыйфаи регламент яисә вазыйфаи күрсәтмә нигезендә тикшерүдә тоту төре буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шул исәптән тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чараларын уздыру аның вазыйфаи бурычларына карый торган, тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чарасын уздырган һәм тикшерү кәгазен тутырган Министрлыкның вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары __________________________________

14. Аларга бирелгән җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган зарури таләпләрнең эчтәлеген чагылдырган тикшерү сораулары исемлеге:

| Т/с | Зарури таләпләрнең эчтәлеген чагылдыручы сораулар | Зарури таләпләрне билгели торган норматив хокукый актларның, аларның бүленеш берәмлекләрен күрсәтеп, белешмәләре | Сорауларга җаваплар | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | әйе | юк | кулланып булмый | |
| Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлык өлкәсендә гомуми таләпләр | | | | | | |
| 1. | Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый яки күрсәтә ала торган хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашырганда карарлар кабул итү өчен җаваплы оешма җитәкчеләре һәм белгечләр әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлык | «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ санлы федераль законның (алга таба – 7-ФЗ санлы федераль закон) 73 статьясының 1 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | өлкәсендә әзерлеккә ияме? | | | | | |
| 2. | Җитештерүдә экология тикшерүендә тоту программасы (II һәм III категорияле объектларда эшчәнлек) расланганмы? | 7-ФЗ санлы федераль законның 67 статьясындагы 2 пункты | | | | |
| Калдыклар белән эш итү | | | | | | |
| 3. | Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш иткәндә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә таләпләр үтәләме? | 7-ФЗ санлы федераль законның 51 статьясы | | | | |
| 4. | Төсле һәм кара металл калдыклары белән эш итүгә һәм аларны читләштерүгә карата таләпләр үтәләме? | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ санлы федераль законның (алга таба – 89-ФЗ санлы федераль закон) $13^1$ статьясы, «Төсле металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләрен раслау турында» 2001 елның 11 маендагы 370 санлы РФ Хөкүмәте карары, «Кара металл ватыгы һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләрен раслау турында» 2001 елның 11 маендагы 369 санлы РФ Хөкүмәте карары | | | | |
| 5. | Калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы зат барлыкка килгән, утильләштерелгән, зарарсызланган, башка затларга тапшырылган яки башка затлардан алынган, шулай ук | 89-ФЗ санлы федераль законның 19 статьясындагы 1 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | урнаштырылган калдыкларны исәпкә алып барамы? | | | | | |
| 6. | Эшчәнлек зонасында каты коммуналь калдыклар барлыкка килә һәм аларның туплана торган урыннары булган төбәк операторы белән каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешү төзелгәнме? | 89-ФЗ санлы федераль законның $24^{7}$ статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 7. | I - IV класслы куркыныч калдыклар белән эшләү өчен кирәкле һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча бирелгән, I - IV класслы куркыныч калдыкларны җыю, транспортлау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру рөхсәт ителгән затларның квалификациясе турында документлар бармы? | 89-ФЗ санлы федераль законның 15 статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 8. | Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм калдыкларны урнаштыру чикләре проекты (II категорияле әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларда эшчәнлек) эшләнгәнме? | 89-ФЗ санлы федераль законның 11 статьясындагы 2 пункты,<br>Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Калдыклар барлыкка килү нормативлары проектларын һәм аларны урнаштыру чикләрен эшләү буенча методик күрсәтмәләрне һәм аларны урнаштыру чикләрен раслау турында» 2020 елның 7 декабрендәге 1021 санлы боерыгы | | | | |
| Атмосфера һавасын саклау | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 9. | Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгару чыганаклары булган юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тискәре метеорологик шартлар фаразларын алганда, Министрлык белән килештерелгән атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруны киметү чаралары үткәреләме? | «Атмосфера һавасын саклау турында» 1999 елның 4 маендагы 96-ФЗ санлы федераль законның (алга таба – 96-ФЗ санлы федераль закон) 19 статьясының 3 пункты | | | | |
| 10. | Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга инвентаризация үткәрү һәм атмосфера һавасына чыгаруга рөхсәт ителгән чик дәрәҗә ташландыкларны һәм зарарлы физик йогынты ясауның рөхсәт ителгән чик нормативларын эшләү тәэмин ителәме? | 96-ФЗ санлы федераль законның 30 статьясындагы 1 пунктының икенче кызыл юлы | | | | |
| 11. | Атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруны тикшерүдә тоту өчен билгеләнгән газ чистарту җайланмаларыннан файдалану кагыйдәләре үтәләме? | 96-ФЗ санлы федераль законның 30 статьясындагы 1 пунктының сигезенче кызыл юлы | | | | |
| Су объектлары, аларның су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары территорияләре | | | | | | |
| 12. | Гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосасына ирекле керү тәэмин ителгәнме? | Россия Федерациясе Су кодексының (алга таба – РФ Су кодексы) 6 статьясындагы 1, 6 һәм 8 өлешләре | | | | |
| 13. | Судан файдаланучы зат тарафыннан судан файдалану шартнамәсендәге шартлар тулы күләмендә үтәләме? | РФ Су кодексының 13 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты | | | | |
| 14. | Судан файдаланучы зат тарафыннан су объектын файдалануга | РФ Су кодексының 22 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | бирү турындагы карар шартлары үтәләме? | | | | | |
| 15. | Су объектларыннан файдаланганда су объектлары милекчеләре, судан файдаланучылар тарафыннан су объектларыннан су ресурсларын алу (йолып алу) күләмен һәм агынты суларны, шул исәптән дренаж суларын ташлау күләмен, аларның сыйфатын билгеләнгән тәртиптә исәпкә алып бару, су объектларына һәм аларның су саклау зоналарына даими күзәтүләрне алып бару, шулай ук мондый исәпкә алу һәм даими күзәтүләр нәтиҗәләрен Су ресурслары федераль агентлыгының территориаль органына бушлай һәм билгеләнгән чорларда тапшыру йөкләмәләре үтәләме? | РФ Су кодексының 39 статьясындагы 2 өлешенең 5 пункты; Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Су объектлары милекчеләре һәм судан файдаланучылар тарафыннан су объектларыннан су ресурсларын алу (йолып алу) күләмен һәм агынты суларны, шул исәптән дренаж суларын агызу күләмен, аларның сыйфатын исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 903 санлы боерыгы | | | | |
| 16. | Су хуҗалыгы системасыннан файдаланганда, санитар чистартуга, зарарсызландыруга дучар ителмәгән агынты суларны су объектларына агызуны тыю турындагы таләп үтәлеше тәэмин ителгәнме (су объектларына рөхсәт ителгән йогынты нормативларыннан һәм су объектларында зарарлы матдәләрнең рөхсәт ителгән концентрациясе нормативларыннан чыгып)? | РФ Су кодексының 60 статьясындагы 6 өлешенең 1 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 17. | Су бастыру, су басу зоналары чикләрендә зиратларны, үләт базларын, җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру объектларын, химик, шартлаткыч, токсинлы, агулый торган һәм агулы матдәләрне, радиоактив калдыкларны саклау һәм күмү пунктларын урнаштыруны тыю үтәләме? | РФ Су кодексының $67^{1}$ статьясындагы 6 өлешенең 3 пункты | | | | |
| 18. | Зат тарафыннан түбәндәгеләргә карата тыю үтәләме:<br>- су саклау зоналары чикләрендә зиратларны, үләт базларын, җитештерү һәм куллану калдыкларын, химик, шартлаткыч, токсинлы, агулый торган һәм агулы матдәләрне урнаштыру объектларын, радиоактив калдыкларны күмү пунктларын урнаштыру;<br>- су саклау зоналары чикләрендә транспорт чараларының (махсус транспорт чараларыннан тыш) хәрәкәтенә һәм тукталышына, каты өслеге булган юллар буенча хәрәкәт итү һәм юлларда һәм махсус җиһазландырылган урыннарда тукталудан тыш?<br>- ягулык салу станцияләрен, ягулык-майлау материаллары складларын төзү һәм үзгәртеп кору (ягулык | РФ Су кодексының 65 статьясындагы 15 өлеше | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | салу станцияләре, ягулык-майлау материаллары складлары портлар, эчке су юллары, шул исәптән аз сыешлы суднолар кую өчен базалар (корылмалар), Федераль куркынычсызлык хезмәте органнары объектлары территорияләрендә урнашкан очраклардан тыш), транспорт чараларын техник карау һәм ремонтлау өчен файдаланыла торган техник хезмәт күрсәтү станцияләрен төзү һәм үзгәртеп кору; транспорт чараларын юу?<br>- пестицидлар һәм агрохимикатларны саклау (яр буе саклык полосалары чикләреннән читтә диңгез портлары территорияләрендә махсус саклагычларда агрохимикатлар саклаудан тыш), пестицидлар һәм агрохимикатлар куллану?<br>- агынты, шул исәптән дренаж суларын агызу?<br>- гомумтаралган файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару (гомумтаралган файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 санлы Россия Федерациясе Законының 19[1] статьясы нигезендә расланган техник | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | проект нигезендә тауда бүлеп бирелгән һәм (яки) геологик бүлеп бирелгән җирләрдәге җир асты байлыклары турында Россия Федерациясе законнары нигезендә үзләренә бирелгән чикләрдә файдалы казылмаларның башка төрләрен эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыра торган җир астыннан файдаланучы затлар тарафыннан башкарылган очраклардан тыш)? | | | | | |
| 19. | Су объектларының су саклау зонасында урнашкан хуҗалык һәм башка объектларны проектлау, төзү, үзгәртеп корганда, файдаланганда су законнары һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә мондый объектларны су объектларын пычратудан, чүпләүдән, ләмләндерүдән һәм суларны арыкландырудан саклауны тәэмин итүче корылмалар белән тәэмин итү буенча таләпләр тәэмин ителгәнме? | РФ Су кодексының 65 статьясындагы 16 өлеше | | | | |
| 20. | Яр буе саклык полосалары чикләрендә су саклау зоналарына карата билгеләнгән тыюларны үтәү тәэмин ителгәнме:<br>- җирләрне сөрү<br>- юдырыла торган грунтларның өемнәрен урнаштыру<br>- авыл хуҗалыгы | РФ Су кодексының 65 статьясындагы 17 өлеше | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | хайваннарын көтү һәм алар өчен җәйге лагерьлар, ванналар оештыру; | | | | | |
| 21. | Автомобиль һәм башка транспорт чараларын җитештергәндә һәм файдаланганда әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә таләпләр үтәләме? | 7-ФЗ санлы федераль законның 45 статьясы | | | | |